ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 февраля 2018 г. № 803

2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Чаллы» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законга, шәһәр Уставының 41 маддәсенә, Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карарына, Башкарма комитетның «Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезнамәне раслау хакында» 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карарына туры китереп

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең «Чаллы» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастыруны һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 15 февралендәге
803 нче карарына
кушымта

2018-2020 елларга Яр Чаллы шәһәренең
«Чаллы» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет
өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| 1. | Сәламәтләндерү үзәге хезмәтләре (8.00-18.00 сәгатькә кадәр) | сум/сәгать | 450 |
| 2. | Сәламәтләндерү үзәге хезмәтләре (19.00-23.00 сәгатькә кадәр) | сум/сәгать | 500 |
| 3. | Тренажер залы хезмәтләре (12 дәрескә абонемент), зурлар/балалар (18 яшькә кадәр) | сум | 700/600 |
| 4. | Тимераякта массакүләм шуу (боз аренасы), зурлар/балалар (18 яшькә кадәр) | сум/сәгать | 160/80 |
| 5. | Тимераякларны массакүләм шуу сеанслары өчен бирү, зурлар/балалар (18 яшькә кадәр) | сум/сәгать | 40/20 |
| 6. | Тимераякларны үткенләү | пар | 50 |
| 7. | Фигуралы шуу буенча өстәмә гомумүстерү программасы нигезендә укыту | сәгать (академик) | 125,0 |
| 8. | Хоккей буенча өстәмә гомумүстерү программасы нигезендә укыту | сәгать (академик) | 125,0 |
| 9. | Хореография залында дәресләр (18 дәрес аэробика), зурлар/балалар | сум | 700/600 |
| Спорт-масскүләм, спорт-тамаша, театраль-тамаша чаралары оештыру һәм уткәрү | | | |
| 10. | Ачык хоккей кортын бирү (чишенү бүлмәсе белән) | сум/сәгать | 600 |
| 11. | Хоккей матчы – сектор 3,4 (зурлар/балалар) | 1 матч | 100/50 |
| 12. | Хоккей матчы – сектор 2,5 (зурлар/балалар) | 1 матч | 80/40 |
| 13. | Хоккей матчы – сектор 1,6 (зурлар/балалар) | 1 матч | 50/25 |
| 14. | Боз аренасын корпоратив шуу өчен бирү – Төнге хоккей лигасы (НХЛ) | сәгать | 5000 |
| 15. | 100 кешегә кадәр боз аренасын бирү (күңел ачу чаралары) | сәгать | 20 000 |
| 16. | Театраль-тамаша чаралары (концертлар, бозда шоу) | сәгать | 28 100 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова